ЧӘРШӘМБЕ
3 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 77 (5877)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы бүлеге 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

Язгы чәчүне сугышчан хәзерлек белән каршылыйк!

Яз көннән-көн үзенекен итә. Кояшлы көннәр дә, явымлы көннәр дә язны тизләтәләр. Кар эри, басулар ачыла. Чәчүгә чыгу Татарстанның барлык районнары өчен дә бер үк вакытта булу ихтимал.

Без хәзер язгы чәчүгә хәзерлекнең иң җаваплы чорына кердек. Бөтен нәрсә сугышчан хәзерлеккә китерелгән булырга тиеш! Хәзер чәчүгә кайчан чыгу һәм эшне кайсы участкыларда элек башлау турында уйлашу, киңәшләшү көннәре килеп җитте. Чөнки чәчүгә чыгуга сугышчан рәвештә хәзерләнмәү аркасында, чәчүгә чыгуны бер көнгә генә булса да кичектерү, авыз ачып калу, ул гафу ителмәслек хата, үткән елгы ялгышлыкларны кабатлау булыр иде.

Участкылар өлгерүне күзәтеп тору кебек колхоз тормышына гадәт булып кергән практиканы быел да кулланырга кирәк. Колхозларда бу эшне яратучылар, аның энтузиазистлары бар. Алар үз постларында, дозорларда булырга, сигналлар биреп торырга тиешләр.

Билгеле, чәчүгә үз вактында һәм тулы хәзерлек белән чыгуны тәэмин итү өчен һава шартларын, туфрак өлгерешен күзәтеп тору гына җитми.

Чәчүгә үз вактында чыгуны, аны иң кыска срокларда һәм югары сыйфатлы итеп үткәрүне материаль хәзерлек һәм эш көчләрен дөрес урнаштыру хәл итәчәк. Эшнең иң әһәмиятлесе шушында.

Ремонт эшендә алдынгылардан Нөркәй, Актаныш, Мөслим, Әлмәт һәм уннарча башка МТС лар тракторларны инде үзләре эшләячәк участкыларга озаттылар. Кыр эшләре башлану алды белән дәртләнгән тракторчылар үзара социалистик ярыш договорлары төзиләр, тәгәрмәчле трактор белән сезонга 1.000 һәм аннан артык гектар эшләү, ягулыкка экономия ясау буенча конкрет йөкләмәләр алалар. Чистай МТС ының „Доброволец" колхозында эшләячәк иптәш Багаев бригадасы тракторга 1.000 гектар эшләү йөкләмәсен алды. Әлмәт МТС ының иптәш Мостафин бригадасы тракторчыларының йөкләмәсе—1.300 гектар, чылбырлы тракторга—2.800 гектар. Мондый инициаторлар республикабызда меңәрләп санала.

Ләкин шул ук вакытта, Татарстанда әле күпчелек МТС лар тракторларга ремонтны төгәлләгәннәре юк. Ремонт планын 25 нче мартка 70 проценттан да ким үтәгән 16 МТС бар. Планны 80 процентка да үтәмәгән МТС лар—28, гомуми план да шул ук числога 82,6 процентка гына үтәлгән иде.

Шулай, берәүләр тракторлар белән участкыларга китәләр, ә икенчеләре ремонт планын өзеп, чәчүгә хәзерлекне куркыныч астына куялар.

Зөя, Ромадан, Заинский, Чокалы, Поповка, Яңа Чишмә МТС лары хурлыклы рәвештә артта баралар. Бу МТС лар Наркомзем һәм район оешмалары тарафыннан махсус контроль астына алынырга һәм аларны ремонт эшендәге өзеклектән чыгару өчен иң ашыгыч чаралар күрелергә тиеш.

Сүз тракторлар турында барганда атлар турында да бер генә минутка да онтырга ярамый. ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы карары нигезендә, ат көчен тулы файдалану өчен һәрбер колхозда ныклы план булдыру, ат һәм тракторлар көченнән файдалануда ныклы бәйләнеш булдыру һич сүзсез үтәлергә тиешле бурыч булып тора. Моның өчен иң элек бригадир һәм колхоз правлениесе председателе җаваплы. Атларның хәле яхшы булу, атлардан тулы файдалану председательдән һәм бригадирдан соралачак, моның өчен алар җавап бирәчәк.

Чәчү алдының икенче үзәк бурычы—орлык мәсьәләсе. Колхозара һәм районара ярдәмләшү тәртибендә алына торган орлыклар хәзер тиешле колхозларга ташылып беткән булырга, кондициягә җиткерелгән булырга һәм тиешле сортларга алмаштырылган булырга тиеш. Чәчү орлыгы белән колхозара ярдәм итешү кебек гүзәл инициативаны нәтиҗәле иттереп тәмам итик! Орлыкларны ерак участкыларга ташып куюны, аларны яхшы саклауны оештырырга һәм кыр станнарын тулы тәртипкә китерергә кирәк.

Чәчүгә чыгу алдындагы өченче зур һәм җаваплы эш—ул эш көчләрен дөрес урнаштыру, хезмәтне звено нигезендә оештыру. Хәзер һәрбер колхозның, бригаданың, звеноның төгәл эш планы булырга тиеш. Һәр кем үзенең чәчү вактындагы эш урнын яхшы белергә, чәчүгә бүген чыгарга хәзер булырга тиеш инде.

Кайбер колхозлар чәчү алды эшенә керештеләр. Орлыкларны агулау эше башланып бара. Яровойлаштыру эшенә керешәләр. Басуларга коллектив рәвештә чыгып кар суларын тоталар. Тракторчылар, колхозчылар, совхоз эшчеләре үзләренә беркетелгән машиналарны кат-кат тикшерәләр. Чәчү өстендә тоткарсыз эшләү өчен хәзерләнәләр.

Партия оешмалары, җир бүлекләре, МТС һәм совхоз җитәкчеләре барлык колхозчыларны, барлык МТС һәм совхоз эшчеләрен чәчүгә чыгуга сугышчан хәзерлеккә китерү мәсьәләләре тирәсенә тупларга тиешләр. Чәчү алдының һәрбер көне кыйммәт. Бер генә көн дә бушка үтмәскә тиеш.

Беренче апрельдән уңына кадәр колхозларда, МТС һәм совхозларда язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләренең рейде бара. Бу рейдне массовый күләмдә үткәреп, барлык игтибарны чәчүне большевикларча хәзерлек белән каршы алуга туплыйк!

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДУМЫ УКАЗЫ

Закир Вәли улы Тинчурин иптәшне Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Председателе урынбасары итеп билгеләү турында

Закир Вәли улы Тинчурин иптәшне Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Председателе урынбасары итеп билгеләргә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе урынбасары Е. АФАНАСЬЕВА.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре М. ЯКУПОВ

Казан, Кремль,
2 апрель, 1940 ел.

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Федор Максимович Ковальский иптәшне Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Председателе урынбасары итеп билгеләү турында

Федор Максимович Ковальский иптәшне Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Председателе урынбасары итеп билгеләргә.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе урынбасары Е. АФАНАСЬЕВА.
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре М. ЯКУПОВ.

Казан, Кремль.
2 апрель, 1940 ел.

ХРОНИКА

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы 1940 нчы елның 2 нче апрелендә булган указы буенча Хәсән Сөләйман улы Сөләйманов һәм Федор Дмитриевич Садовников иптәшләрне Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Председателе урынбасарлары хезмәтләреннән азат итте.

Язгы чәчү алдыннан

Орлык белән районара ярдәмләшү

ТӘКӘНЕШ. (Телефон буенча). Районда байтак колхозларның кайбер культуралар буенча чәчү орлыгы җитми иде. Күп кенә колхозлар үзләреннән арткан орлыкларын башка колхозларга биреп тору юлы белән 6.000 центнердан артык орлык тупланды. Шулай итеп районның барлык колхозлары да чәчү орлыгы белән тулысынча тәэмин ителде. Чәчү орлыгының 95 проценты чәчүгә яраклы кондициягә китерелде инде.

Хәзер районның колхозлары үзләреннән арткан чәчү орлыкларын башка район колхозларына биреп тору эшен җәелдерделәр. Шушы уңай белән 59 колхозда колхозчыларның гомуми җыелышы үткәрелде. Яңа Каенсар авылы колхозы 200 центнер, „Красный Сутерь" колхозы 200 центнер, Иске Каенсар авылы колхозы 197 центнер, „1 нче Май" колхозы 140 центнер, Ворошилов исемендәге колхоз 195 центнер чәчү орлыгы белән башка район колхозларына ярдәм итәләр. Районара орлык белән ярдәм күрсәтү өчен 4.500 центнер орлык тупланды. Хәзер шуның 75 проценты тиешле пунктларга тапшырылды инде.

Искәндәрев.
ВКП(б) райкомы секретаре.

Орлык агулауга хәзерлек

Мөслим районы колхозлары быел 28.928 центнер чәчү орлыгын формалин белән һәм 2.618 центнер орлыкны термик ысул белән агулап чәчәргә тиешләр.

Хәзер районда орлык агулауга хәзерлек эшләре киң җәелдерелде. Агулау өчен кирәкле формалин тулысынча колхозларга кайтарылды һәм урыннар, инвентарьлар җитәрлек хәзерләнде.

Орлык агулау һәм яровойлаштыру өчен бишкөнлек курсларда 141 кеше хәзерләнде. Бу эшләрне башкару өчен кадрлар җитәрлек.

Шуның белән бергә, бәрәңге яровойлаштыруга хәзерлек буенча районда җитешсезлекләр дә бар әле. „Зар усы" һәм „Красный Октябрь" колхозларында бәрәңге яровойлаштыру өчен урыннар да хәзерләнмәгән әле.

Х. Шәйми.

Колхозчылар массовый күләмдә кар суы тотуга чыктылар

29 нчы мартта партия һәм комсомол оешмалары Юдино районының күп кенә колхозларында кар сулары тоту өчен колхозчыларның массовый күләмдә кырга чыгуын оештырдылар.

„Яңалиф" колхозында кар суы тотуга 124 кеше чыкты. Комсомолец иптәш Гайнуллин звеносы стахановча эш үрнәкләре күрсәтте. 18 колхозчыдан торган бу эшләр звеносы 17 гектар мәйданда (кар өемнәре ясау юлы белән) кар суы тотуны тәмамлады. Звеноның эше яхшы дип табылды. Бер көн эчендә „Яңалиф" колхозында 78 гектар мәйданда кар суы тотылды.

Бу көнне „Урал" колхозында 78 кеше кырга чыкты һәм алар 62 гектар җирдә кар суы тоттылар.

Олы Яке авыл советының 3 колхозында 100 гектардан артык җирдә кар суы тоту үткәрелде.

Районның башка колхозларында да бу көнне массовый рәвештә кырга чыгу оештырылды. 29 нчы мартта 11 колхозда 434 гектар мәйданда кар суы тоту үткәрелде. (ТатТАСС).

ЭШЧЕ-АВЫЛ ХӘБӘРЧЕЛӘРЕ РЕЙДЕ

МАМАДЫШ, 2 апрель. (Телефон буенча). Рейд бригадасы „Хәснуллин" колхозының язгы чәчүгә хәзерлеген яхшы дип тапты. Бу колхоз үткән елны беренчеләр рәтендә культураларның һәр гектарыннан уртача 13 центнер 59 килограмм иген уңышы алган иде. Быел колхозчылар һәрбер гектардан уртача 120 пот иген уңышы алуга ирешү өчен йөкләмә алдылар. Моңа ирешү өчен нык хәзерлек күрү эшләре яхшы алып барыла.

Орлыклар чистартылган һәм яхшы урыннарда саклыналар. Машиналарга һәм башка инвентарьларга ремонт эше төгәлләнгән. Орлыкларны яровойлаштыру эшенә хәзерлек канәгатьләнерлек.

Аерым колхозчылар арасында шулай ук бригадалар арасында социалистик ярыш киң җәелдерелгән. Бригадалар арасында договорларның үтәлеше белән кызыксынганнар. Ярышта иптәш Юнусов бригадасы алда бара. Колхозның стахановчы тимерчесе Сәгыйт Зиннәтуллин машиналарга ремонт ясау планын билгеләнгән сроктан 15 көн алда төгәлләгән. Атларның язгы чәчү эшенә хәзерлектә ат караучы иптәш Сиражиев алда бара. Ул карый торган атлар көр. Җирле ашламалар хәзерләүдә Хәбиб Мөбарәкҗанов колхозда мактаулы урыннарның берсен алган.

Рейд членнары: Гыйлметдинов, Кадыйханов, Корбанов, Насыйбуллин, Мөбарәкшин.

* *

Заинский районының „Кызыл Октябрь" колхозында, 30 нчы мартта язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча авыл хәбәрчеләре рейде үткәрелде. Рейдтә авыл хәбәрчеләреннән 7 кеше, авыл советы депутаты Талипов, укытучылар Кириллов һәм Тажеттинов иптәшләр катнаштылар.

Тикшерү „Кызыл Октябрь" колхозының чәчүгә яхшы гына хәзерләнгәнлеген күрсәтте. Чәчүлек орлыклар тазартылган, тикшерелгән һәм коры биналарда саклаланалар. Атлар уртача көрлектә. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясалган, агрономиянең кышкы чаралары үтәлгән.

Колхозда җитешсезлекләр дә бар әле. Мәсәлән, звенолар формаль рәвештә генә төзелгәннәр, бу эштә Чыбыклы МТС ының агрономнары колхозга ярдәм итмиләр.

* *

САБА, 2 апрель. (Телефон буенча). Язгы чәчүгә хәзерлекне тикшерү буенча эшче-авыл хәбәрчеләре рейде бара. Рейдта Саба районы „Колхоз байрагы" газетасы чиктән тыш активсызлык күрсәтә.

Райком бюросы рейд оештыру турында 1 нче апрельдә карар кабул итте. Ләкин район газетасы эшенә, рейдне оештыруга райкомның да, район башкарма комитетының да контрольлекләре, җитәкчелекләре җитәрлек түгел. Рейд бригадалары җитәкчеләре итеп 1 нче апрельдә үткәрелгән инструктаж киңәшмәсенә районның 73 колхозыннан бары тик 25 кеше вәкилләр килде. Шуңлыктан, рейд бригадалары фактта бүгенге көнгә кадәр тик 25 кенә колхозларда гына эшкә башладылар.

Г. Хәбиб.

* *

ВКП(б) нең Кызыл Армия район комитеты һәм район советы башкарма комитеты колхозларның язгы чәчүгә хәзерлекләрен тикшерү өчен 23 тикшерү бригадасы оештырдылар. Бу бригадаларга район газетасының һәм колхозлардагы стена газеталарының 70 тән артык авыл хәбәрчеләре керде.

31 нче мартта райком рейдта катнашучы эшче-авыл хәбәрчеләренең инструктив киңәшмәсен үткәрде. Беренче апрельдә эшче-авыл хәбәрчеләре рейд эшенә керештеләр. (ТатТАСС).

Кукмара районы „Азьлань" колхозының ефремовчы звеносы, звеноның агротехника планын өйрәнә. Алгы планда агротехник И. Никитин (уңда) һәм звено башлыгы А. Шахтина иптәшләр. Д. Невзоров фотосы.

СМОТР

Киров исемендәге колхозда шушы арада булып үткән смотр, колхозның язгы чәчүгә нигездә яхшы хәзерләнгән булуын күрсәтте. Районадагы җитәкче оешмаларның вәкилләре, колхозның бригадалары һәм стахановчылары катнашы белән үткәрелгән смотр I, II, III, IV, V һәм IX нчы бригадаларны язгы чәчүгә отлично хәзерләнгәннәр дип тапты. Алар бүгенгә үк чәчүгә чыгарга хәзерләр. Язгы чәчү өчен кирәкле нәрсәләрнең һәммәсе хәзер.

Авыл хуҗалыгы машиналары отлично итеп хәзерләнгәннәр. Машиналар өчен запас частьлар, машина ачкычлары, запас шөрепләр тартмаларга тутырып куелган. Чәчү машиналарының сошникларын бармак белән тартмас өчен тимердән сантиметрлар, җирләрне үлчәү өчен тимердән метрлар эшләнеп, бригада номерлары сугылган. Арбалар, сбруйлар бүген походка чыгарлык итеп, бик яхшы хәзерләнгәннәр. Дилбегә башларына тимерләр куелган. Капчыклар юылып, сырланнан чистартылып, дезинфекция ясап куелган. Капчык ямаулары, инәләр һәм җепләр хәзерләнгән. Язгы чәчү вактында бригададан бригадага чабып йөрмәс өчен „вак-төяк" нәрсәләрнең дә һәммәсе хәзерләнгән.

Кырда аш пешерүчеләр өчен ак калпаклар кесәле итеп һәм бригада номерлары сугып, алъяпкычлар тегелгән. Кыр кухнялары, эмальле савыт-сабалар, борчак һәм бәрәңге төю өчен тукмаклар, капкачлы тоз савытлары һәм башкалар һәммәсе чиста итеп хәзерләп куелганнар. Су ташу һәм ягулык хәзерләү өчен аерым чиләкләр, мичкәләр һәм ат хәзерләнгән. Кырда культура хезмәте күрсәтүгә кирәкле нәрсәләрне саклау өчен шкафлар эшләнгән. Һәр бригада өчен кәгазьләр, сәгатьләр, авыл хуҗалыгы турындагы китаплар, юлбашчыларның рәсемнәре, стена газеталары өчен макетлар һәм рамнар, стена газеталары кадап кую өчен кнопкалар хәзерләнгән. Юып кую өчен кирәкле бөтен нәрсәләр, кыр станнарында производство киңәшмәләре үткәрү өчен язу лампалар алынган. Ярыш такталары буяп куелган. Колхозның бригадаларында стахановчылардан төзелгән 12 кешелек агитбригада кыр эшләре вактында бригадаларга культура хезмәте күрсәтәчәкләр. Шуның өстенә, IV, VI һәм IX нчы бригадаларда гармоннар, III һәм V нче бригадаларның патефоннары бар.

Колхоздагы 12 бригаданың калганнары смотрны тулы хәзерлек белән каршы алмаганнар. VIII нче бригадада 2 сабанга ремонт ясалмаганлыктан, смотр комиссиясе аларны яңадан мастерскойга җибәртте. Культиваторлар һәм 2 төргән сабаннар су керә торган лапаска куелганлыктан комиссия аларны башка лапаска күчертте. Х нчы бригаданың машиналарына ремонт яхшы ясалган, ләкин алар майлап куелмаганнар. Комиссиянең тәкъдиме буенча машиналар бер көн эчендә майландылар. Машиналар сарае чиләк белән сүндерелгән ... куелган иде. Комиссия бу кирүгә кисәтү ясады.

Чәчү орлыкларының сыйфаты һәм саклануны белгечләр һәм төрле комиссияләр тарафыннан 7 тапкыр тикшерелеп, яхшы дип тапылган. Смотр комиссиясе бригадаларны бик яхшы саклануны дип тапты һәм бу турыда амбар кенәгәләренә язып куйды. Амбарлар кар суыннан саклау өчен нык итеп ябылган. Смотр вактында амбар тирәсен карап ... тәкъдим итте. ... үтмәсен өчен ... тирәсенә сакчы куелган.

Агротехника чараларын үтәүдә дә зур гына уңышлар бар. Колхоз 23 нче мартка кадәр 20.5... йөк тирес чыгарып, планны арттырып үтәгән. Тирес сыекчасы хәзерләү планы 116 процент, ... тоту планы 111 процент, ... хәзерләү планы 177 процент үтәлгән. Планнарны беренче тапкыр арттырып үтәгән бригадалар ...

Машиналарны барсы да ремонт чыгып, атлар белән ... бул ителгәннәр. Бөтен кирәкле ... хәзерләнгән белән 150 камыт ... гән, 50 арба хәзерләнгән.

Кырда беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен 12 кеше укып җибәрелгән. Тракторчылар ... лары ягулыгы белән хәзерләнгән. Комбайнчылар курсында 4 кеше укый. Өч автомашина өчен шоферлар хәзер. Яровойлаштыру курсында 12 кеше укый. Бр... яровойлаштыру эшен механикалаштыру өчен хәзерлек бу... Элек су тышта кулдан ... натылган булса, механикалаштырганнан соң кирәкле температура тоту өчен ... күләмдә пар белән кайнатылачак.

Колхозда массовый-политик ... яхшы куелган. 22 агитатор систематик рәвештә эшли. ... колхозчыларның гомуми җыелышында Татарстанның башка колхозларга орлык белән социалистик үзара ярдәм мәсьәләсе куелганда 570 центнер орлык бирү турындагы тәкъдимне бер тавыштан кабул иттеләр. Шуның өстенә, алар күрше колхозлар Кече Этнә, Соңгыр һәм Бай... колхозларга ярдәм итү өчен ... булырга булдылар. ... факт колхозчыларның ... ярдәм күрсәтүгә ... күрсәтте. Колхоз быел да Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашырга ... кандидат. Колхозчылар ... бу уңыш өчен көрәш дәрте белән кайныйлар. Йөзпотчылар ... актив катнашу, алар ... тагын да югарырак уңыш алу өчен ярышалар.

Н. Мансуров.
(Этнә районы).

Ярыш договорының үтәлешен тикшерде...

Кукмара районы, „Спартак" колхозы делегациясе колхозара төзелгән социалистик ярыш договорының Стаханов исемендәге колхозда ничек үтәлүен тикшерде.

Делегация бу колхозның язгы чәчүгә хәзерлеген канәгатьләнерлек, дип тапты. Колхозда кышкы агротехника чаралары уңышлы үткәрелгән. Колхозчылар арасында масса-агитация эшләре алып баруга нык әһәмият бирелә. Бригадалар һәм звенолар арасында төзелгән социалистик ярыш договорларының үтәлешен системалы рәвештә тикшерелә.

Быел ефремовчы уңыш ... турында йөкләмә алган ... звено 9 центнер урыш һәм ... центнер ясмык орлыгы ... чистартып тартканнар. Җирле ашламалар хәзерләүдә дә звенолар ... кенә уңышлы эшләр бар.

Г. Сибгатулли...

СССР НЫҢ I НЧЕ ЧАКЫРЫЛЫШ ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫНЫҢ АЛТЫНЧЫ СЕССИЯСЕ

Союз Советының Мандат Комиссиясе доклады

Докладчы депутат А. С. ЩЕРБАКОВ

Депутат иптәшләр! Үткән V нче ссиядә СССР Верховный Сове- Көнбатыш Украинаны һәм нбатыш Белоруссияне Украина м Белоруссия Совет Социалисик Республикаларга кушып Сот Социалистик Республикалар юзы составына кертү турында энбатыш Украина һәм Көнбаш Белоруссия Халык Собраеләренең үтенечләрен канәгатндергән иде.

Кардәш украинлылар һәм белослар белән бергә кушылу тунда Көнбатыш Украина һәм нбатыш Белоруссия хезмәт ләренең мәңгелек хыялы торшка ашты.

Поляк буржуазиясе һәм алпатлары изүеннән азат ителгән нбатыш Украина һәм Көнбатыш елоруссия хезмәт ияләре бөек оветлар Союзы халыкларының рдәш семьясенә кушылдылар, челәрнең һәм крестьяннарнең циалистик дәүләтендә тигез кукл ы граждан нар булып әвеләделәр.

1940 нчы елның 24 нче мартын Украина ССР ның һәм Белоссия ССР ның көнбатыш өлкәрендәге халыклар дөньядагы демократик Сталин Конституясе нигезендә беренче тапкыр ларак Совет Социалистик Республикалар Союзы Верховный оветына үзләренең депутатлаын сайладылар.

Союз Советының беренче Сессиясендә сайланган Мандат Комиссия-, СССР Конституциясенең нче статьясе нигезендә, округ ләмендәге сайлау комиссияләре рафыннан һәрбер депутатка рата бирелгән сайлау документрын һәм материалларын тикрде.

„СССР Верховный Советына йлаулар турында положение" ң 44 нче статьясенең „в" пункты ләпләренә туры китереп, Союз ветының Мандат Комиссиясе путатлыкка кандидатларны тер протоколларын, шулай ук таш бирү протоколларын тикрде.

Һәрбер депутатка карата докунтларны һәм материалларны кшергәннән соң Мандат Комиссиясе Украина ССР ның һәм елоруссия ССР ның көнбатыш кәләрендәге 43 сайлау округың барсыннан да Союз Совена депутатлар сайлауның СССР нституциясе һәм „СССР Верный Советына сайлаулар турындагы положение" нигезендә м шуларга туры китереп үткәлгәнлеген белде.

Мандат Комиссиясе шулай ук нди булса да округ буенча йлауларны дөрес түгел дип барга сәбәпләр юклыкны, шуй ук нинди булса да округтан юз Советына депутатлар сайуны шик астына куярлык бернди жалобалар һәм заявлениер юклыкны билгеләде.

Союз Советына Украина ССР ың һәм Белоруссия ССР ның нбатыш өлкәләреннән сайлан н депутатларның составын күртә торган саннарны китерергә хсәт итегез. 43 сайлау округыннан Союз Советына 43 депут сайланган.

Депутатларның социаль составы түбәндәгечә:

эшчеләр—19 кеше, яки 44 процент;

крестьяннәр—14 кеше, яки 33 процент;

интеллигенция—10 кеше, яки 23 процент.

Эшчеләрдән һәм крестьяннәрән булган депутатларның бер еше партия, профсоюз, совет ендә һәм хәрби эштә эшли.

Сайланган депутатлар поляк алвытларына һәм капиталистлаына каршы көрәшчеләр сыйфаында сайлаучыларга таныш, аларың күбесе төрмәләрдә утырганр, поляк охранниклары тараыннан җәзаланганнар, азатлык ендә Кызыл Армиягә ярдәм итәннәр. Хәзер алар бөек хөрмәт—халык вәкиле булу бәхтенә рештеләр.

Кызыл Армия килгәннән соң депутатлар Совет власте төзү өчен, оциализм өчен көрәштә үзләрен тив җәмагать эшчеләре итеп рсәттеләр. Алар киң катлау лыклар массасы арасыннан тив политик эшкә күтәрелделәр м хәзер дәүләт органнарында ышлы эшлиләр, предприятиергә, культура учреждениеләренә итәкчелек итәләр, Көнбатыш Укаина һәм Көнбатыш Белоурссия лыкларына армый - талмый а, азат һәм шатлыклы тормыш эзиләр. Халык аларның эшенә гары бәя бирде һәм Верховный оветка сайлаулар көнендә алар зур ышаныч белдерде.

Милли составы ягыннан депутатлар арасында украинлылар, белоруслар, поляклар һәм руслар бар. Депутатларның милли составы Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыкларының хәзер анда Сталинчыл дуслыгын гәүдәләндерә. Барлык милләтләр совет парламентына сайлауда һәм сайлануда тигез хокук алдылар.

Депутатлар арасында хатын-

кызлар 11 кеше, яки 26 процент. Алар ирләр белән бер тигез хокукларда дәүләт эшенә сайланганнар. Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия хатын-кызларына безнең бөек Ватаныбыздагы хатын-кызларда булган кебек киң хокуклардан файдалану мөмкинлеген бары тик Совет власте гына бирде.

Союз Советына яңа сайланган депутатлар арасында югары белемлеләр—11 кеше (26 процент), урта белемлеләр—6 кеше (14 процент), түбән белемлеләр—26 кеше (60 процент).

Украинаның көнбатыш өлкәләреннән һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләреннән Союз Советына сайланган депутатларның яшьләре түбәндәгечә:

18 яштән 25 яшькә кадәр—1 кеше,
26 яштән 40 яшькә кадәр—30 кеше,
40 яштән олылар—12 кеше.

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә 7.966.923 сайлаучыдан 1940 нчы елның 24 нче мартында Союз Советына депутатлар сайлауда 7.894.971 кеше катнашты, бу—барлык сайлаучыларның 99,09 проценты.

Шулай итеп, дәүләт властеның верховный органнарына депутатлар сайлауларда Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендәге сайлаучылар барсы да диярлек катнаштылар.

Эшчеләр, крестьяннәр, интеллигенция, ирләр һәм хатын-кызлар беренче тапкыр буларак үзләренең халык вәкилләрен иректе рәвештә сайладылар. Алар үзләренең гражданлык бурычларын югары дәрәҗәдә җаваплылык хисе белән үтәделәр һәм шулай итеп Совет властена үзләренең ышанычларын тагын һәм тагын бер кат белдерделәр, үзләренең социалистик Ватаннарына чиксез һәм кайнар мәхәббәтләрен күрсәттеләр.

Шул уңай белән элекке паннар Польшасында миллионнарча хезмәт ияләренең сайлау хокукларыннан мәхрум ителгән булганлыкларын искә алып үтү артык булмас. Йөз меңнәрчә кешеләр сайлауларга бойкот иглан итеп үзләренә дошман булган властька карашлары нинди икәнлекне белдерәләр иде. 1935 нче елны Польша сеймына сайлауларда бөтен Польшада сайлаучыларның бары 46 проценты гына тавыш бирде. Кайбер районнарда исә тавыш бирүдә сайлаучыларның 3 проценты гына катнашты. Дөрес түгел дип табылган бюллетеннәр 50 процентка җитә иде.

1940 нчы елның 24 нче мартында Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия хезмәт ияләре беренче тапкыр буларак халыкның чын вәкилләрен сайладылар.

Барлык 43 сайлау округында Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән Союз Советына сайлауларда коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларын яклап 7.743.210 сайлаучы тавыш бирде. Бу тавыш бирүдә катнашкан барлык сайлаучыларның 98 процентыннан артыграгы.

Союз Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайланган депутатлар арасында Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе членнары—14 кеше, яки 32,6 процент, партиясезләр—29 кеше, яки 67,4 процент.

Бу саннар коммунистлар һәм партиясезләр блогының тулысынча җиңүен күрсәтәләр.

Коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларына бердәм тавыш бирү—ул, Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыкларының барлык сугыш уты кабызучыларга җавабы, ул Совет хөкүмәтенең зирәк тышкы политикасын яклауның яңа күрсәткече.

Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыклары коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларына бердәм рәвештә тавыш бирүләре белән Ленин—Сталин партиясенә, Совет хөкүмәтенә үзләренең чиксез ышануларын, илебезне җиңүгә—коммунизмга алып баручыга—юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталинга үзләренең кайнар мәхәббәтләрен тагын һәм тагын бер кат күрсәттеләр.

Депутат иптәшләр! Союз Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайланган депутатларның полномочиеләрен тикшерү нәтиҗәсендә, Союз Советының Мандат Комиссиясе түбәндәге карарны кабул итте һәм аны сезнең карамагыгызга кертә:

„Һәрбер депутатка булган барлык сайлау документларын һәм Союз Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайлаулар буенча округ күләмендәге сайлау комиссияләре тарафыннан бирелгән барлык материалларны аерым рәвештә тикшереп, Союз Советының Мандат Комиссиясе түбәндәгеләрне билгели:

1. Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә 43 сайлау округының барсында да Союз Советына депутатлар сайлау СССР Конституциясе һәм „СССР Верховный Советына сайлаулар турындагы положение" нигезендә һәм шуларга тулысынча туры китереп үткәрелгән.

2. Сайлауларны дөрес түгел дип табарга һичбер төрле нигез юк, шулай ук Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән Союз Советына депутатлар сайлаганда нинди булса да сайлау округында СССР Конституциясен һәм сайлаулар турындагы положениене бозулар турында һичбер жалоба һәм белдерү юк.

Шушы әйтелгәннәр нигезендә, Союз Советының Мандат Комиссиясе Союз Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайланган һәм исемлекләре „Известия" нең 1940 нчы ел, 28 нче мартындагы 72 нче номерында иглан ителгән депутатларның барсының да полномочиеләрен дөрес дип таба".

Милләтләр Советының Мандат Комиссиясе доклады

Докладчы депутат М. А. БУРМИСТЕНКО

Депутат иптәшләр! Моннан алты ай элек Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыклары тормышында тарихи үзгәрешләр булды. Данлыклы Кызыл Армия Совет хөкүмәтенең тапшыруы буенча Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыкларын капиталистик коллыктан, Польшаның булдыксыз хөкүмәте тарафыннан башланган сугыштан азат итте (**кул чабулар**), һәм аларга тынычлык, тулы милли һәм политик азатлык, чын-чыннан иректе һәм яңа, шатлыклы тормыш алып килде.

Азат ителгән халыклар Совет власте урнаштыруны иглан иттеләр, Советлар иленең бөек социалистик семьясенә кушылдылар һәм дөньяда иң демократик Конституция булган Сталин Конституциясе байрагы астына бастылар.

1940 нчы елның 24 нче мартында эшчеләр, крестьяннәр, интеллигенция, нинди расадан һәм нинди милләттән булуларына карамастан, гомуми, тигез һәм туры сайлау хокукы нигезендә яшрен тавыш бирү тәртибендә Милләтләр Советына үзләренең депутатларын сайладылар.

Милләтләр Советының беренче Сессиясе тарафыннан сайланган Мандат Комиссиясе, СССР Конституциясенең 50 нче статьясе нигезендә, „СССР Верховный Советына сайлаулар турындагы положение"нең 48 нче статьясенең „а" пункты таләпләренә туры китереп һәрбер депутатка округ сайлау комиссияләре тарафыннан бирелгән барлык сайлау документларын һәм материалларын, ягни депутатларны теркәү турындагы протоколларның барлыгын һәм тавыш бирү протоколларының барлыгын тикшерде.

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә Милләтләр Советына сайлаулар буенча 12 сайлау округы төзелгән иде.

Мандат Комиссиясе, һәрбер депутатка карата документларны һәм материалларны тикшергәннән соң барлык 12 сайлау округларында да Милләтләр Советына депутатлар сайлау СССР Конституциясе һәм „СССР Верховный Советына сайлаулар турындагы положение" нигезендә һәм аларга туры китереп үткәрелгән дип билгеләде.

Мандат Комиссиясе шулай ук, нинди булса да округ буенча сайлауларны дөрес түгел дип табарга һичбер төрле нигезләр булмаганлыкны, нинди дә булса округ буенча Милләтләр Советына депутатлар сайлауны шик астына куярлык жалобалар һәм гаризалар булмаганлыкны билгеләде.

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләре хезмәт ияләреннән Милләтләр Советына җибәрелгән вәкилләр азат ителгән халыкның, үзләренең кардәш туганнары белән бердәм Совет дәүләтенә берләшкән халыкның иң яхшы кешеләре. Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыклары поляк паннарының политик һәм милли изүләренең авырлыкларын үзләрендә сынадылар. Хәзер, бу изүләр һәм тигезсезлекләр юк ителгәч, Советлар Украинасының һәм Советлар Белоруссиясенең көнбатыш өлкәләрендәге халыклар үзләренең формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураларын иректе рәвештә үстерү өчен мөмкинлек алдылар.

Милләтләр Советына сайланган депутатлар арасында украинлылар, белоруслар, поляклар бар.

Милләтләр Советы депутатларының социаль составы түбәндәгечә: эшчеләр—3 кеше, яки 25 процент, крестьяннәр—3 кеше, яки 25 процент, интеллигенция—6 кеше, яки 50 процент. Милләтләр Советы депутатлары составында ирләр—11 һәм хатын-кызлар 1 кеше. Милләтләр Советы депутатларының яшьләре турындагы мәгълүматлар депутатларның күпчелек өлешенең 40 яштән карт булмавын, ягъни 26 дан 40 яшькә кадәр—10 кеше, 40 яштән югарылар—2 кеше булганлыгын күрсәтәләр.

Милләтләр Советына сайланган депутатлар арасында югары белемлеләр—3 кеше, яки 25 процент, урта белемлеләр—2 кеше, яки 16,7 процент, түбән белемлеләр—7 кеше, яки 58,3 процент.

Милләтләр Советы депутатлары арасында Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе членнары—4 кеше, яки 33,3 процент һәм партиясезләр—8 кеше, яки 66,7 процент.

Сайланган депутатлар арасында партия работниклары 2 кеше, совет работниклары—8 кеше, укытучылар 1 кеше һәм авыл хуҗалыгында эшләүче крестьяннәр—1 кеше.

Милләтләр Советына яңа сайланган депутатларның күбесе озак еллар буена элекке Польшада капиталистик коллыкка каршы нык лы һәм аяусыз көрәш алып барганнар. Алар революцион хәрәкәттә катнашканнар, массаны алпавытларга, капиталистларга каршы көрәшкә оештырганнар, полиция репрессияләренә, һәр төрле эзәрлекләүләргә дучар ителгәннәр, кыйналганнар, төрмәләрдә утырганнар. Ләкин бер нинди көч тә аларның көрәшкә һәм җиңүгә булган омтылышларын сындыра алмады.

Хәзер халыклар массасы аларны иң яхшылардан яхшылары сыйфатында, хезмәт ияләре эшенә аеруча бирелгән кешеләр сыйфатында, халык дошманнарына каршы актив көрәшергә, социализм эше өчен көрәшергә, бөек Ватаныбызның бердәм күп милләтле халыклары семьясендә бер сафларда барырга сәләтле булган кешеләр сыйфатында дәүләт властеның югары органнарына күтәрделәр.

Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендәге 7.966.923 сайлаучыдан Милләтләр Советына депутатлар сайлауларда 7.895.861 кеше катнашты, бу—барлык сайлаучылар санына карата 99,1 процент.

Милләтләр Советына сайлаулар буенча барлык 12 сайлау округында коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларына 7.743.965 сайлаучы тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан барлык сайлаучыларның 98,07 проценты.

Украинаның көнбатыш өлкәләрендәге һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендәге хезмәт ияләре коммунистлар һәм партиясезләр блогы кандидатларына үзләренең тавышларын бердәм рәвештә бирделәр, бу Көнбатыш Белоруссиянең һәм Көнбатыш Украинаның азат ителгән халыкларының бөек Ленин—Сталин партиясенә, Совет хөкүмәтенә, партиянең һәм СССР халыкларының бөек юлбашчысына, илебезне коммунизмның яңадан-яңа җиңүләренә алып баручыга,—даһиебыз иптәш Сталинга гаять зур, чиксез ышанычының яңа күрсәткече. (**Барсы да урыннарыннан торалар, көчле кул чабулар алкышларга күчә**).

Белоруссиянең һәм Украинаның көнбатыш өлкәләрендәге хезмәт ияләре яңа, бәхетле тормыш өчен, Сталинчыл милли политика өчен, социалистик төзелеш өчен, Ленин—Сталинның большевистик партиясе өчен, Совет хөкүмәтенең зирәк тышкы политикасы өчен тавыш бирделәр. Алар сугышка каршы, сугыш уты кабызучыларга каршы, үзләренә дошман булган капиталистик стройга каршы тавыш бирделәр.

Депутат иптәшләр! Милләтләр Советының беренче Сессиясендә сайланган Мандат Комиссиясе Милләтләр Советы депутатларының полномочиеләрен һәм Украина Совет Социалистик Республикасының һәм Белоруссия Совет Социалистик Республикасының көнбатыш өлкәләреннән сайланган һәрбер депутатка карата округ сайлау комиссияләре тарафыннан бирелгән барлык сайлау документларын һәм материалларын тикшерде.

Милләтләр Советының Мандат Комиссиясе түбәндәге карарны кабул итте һәм ул сезнең карамагыгызга кертелә:

„Һәрбер депутатка булган барлык сайлау документларын һәм Милләтләр Советына Украина ССР ның һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләреннән сайлаулар буенча округ күләмендәге сайлау комиссияләре тарафыннан бирелгән барлык материалларны аерым рәвештә тикшереп, Милләтләр Советының Мандат Комиссиясе түбәндәгеләрне билгели:

1. Украина Совет Социалистик Республикасының һәм Белоруссия Совет Социалистик Республикасының көнбатыш өлкәләрендә 12 сайлау округының барсында да Милләтләр Советына депутатлар сайлау СССР Конституциясе һәм „СССР Верховный Советына сайлаулар турындагы положение" нигезендә һәм шуларга тулысынча туры китереп үткәрелгән.

2. Сайлауларны дөрес түгел дип табарга һичбер төрле нигез юк, шулай ук Украина Совет Социалистик Республикасының һәм Белоруссия Совет Социалистик Республикасының көнбатыш өлкәләреннән Милләтләр Советына депутатлар сайлаганда нинди булса да сайлау округында СССР Конституциясен һәм сайлаулар турындагы положениене бозулар турында һичбер жалоба һәм белдерү юк.

Шушы әйтелгәннәр нигезендә, Милләтләр Советының Мандат Комиссиясе Милләтләр Советына Украина Совет Социалистик Республикасының һәм Белоруссия Совет Социалистик Республикасының көнбатыш өлкәләреннән сайланган һәм исемлекләре „Известия" нең 1940 нчы ел, 28 нче мартындагы 72 нче номерында иглан ителгән депутатларның барсының да полномочиеләрен дөрес дип таба".

СОЮЗ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

1 апрель, 1940 ел

1 нче апрельдә, көндез 11 сәгаттә, Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында Союз Советының икенче утырышы булды.

Утырышта Союз Советы Председателенең урынбасары депутат **Т. Д. Лысенко** председательлек итә.

Союз Советы көн тәртибенең өченче пункты буенча СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турында Союз Советының Бюджет Комиссиясенең өстәмә докладын тыңлый. Бу докладны депутат **К. И. Николаева** ясый.

Бюджет комиссиясенең өстәмә докладыннан соң Союз Советы СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты һәм СССР ның 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы доклад буенча фикер алышуларга күчә.

Фикер алышуларда депутатлардан **Т. И. Кулиев** (Азербайҗан ССР ның Сабир-Абад округы), **Л. Р. Корниец** (УССР ның Волын өлкәсе, Камень-Каширск округы), Үзбәкстан ССР Совнаркомы председателе иптәш **А. Абдрахманов**, РСФСР Совнаркомы председателенең урынбасары иптәш **А. А. Пекшев**, СССР ның Сәламәтлек Саклау Халык Комиссары иптәш **Г. А. Митерев**, депутатлардан **Т. В. Федорова** (Москва шәһәренең Советский округы) һәм **А. С. Пирузян** (Әрмәнстан ССР ның Кировакан округы) катнаштылар.

Шуның белән Союз Советының икенче утырышы ябыла.

МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

1 апрель, 1940 ел

1 нче апрельдә, кич 6 сәгаттә, Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында Милләтләр Советының икенче утырышы булды.

Утырышта Милләтләр Советы Председателенең урынбасары депутат **Ч. А. Асланова** председательлек итә.

Милләтләр Советы көн тәртибенең 3 нче пункты буенча СССР ның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турында Милләтләр Советының Бюджет Комиссиясе председателе депутат **И. С. Хохловның** өстәмә докладын тыңлый.

Бюджет Комиссиясенең өстәмә докладын тыңлаганнан соң Милләтләр Советы СССРның 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты һәм СССР ның 1938 нче елгы дәүләт бюджетының үтәлеше турындагы доклад буенча фикер алышуларга күчә.

Фикер алышуларда депутатлардан **В. Г. Ванеев** (Белоруссия ССР ның Минск шәһәр округы), **М. К. Делба** (Абхазия АССР ның Гудауты округы) һәм **М. Нурбаев** (Кыргызстан ССР ның Узген округы), СССР ның Ит һәм Сөт промышленносте Халык Комиссары иптәш **П. В. Смирнов**, депутатлардан **М. Авезова** (Таҗикстан ССР ның Ленинабад шәһәр округы) һәм **З. Х. Харисов** (Татарстан АССР ның Бөгелмә округы) һәм СССР Совнаркомы янындагы югары мәктәп эшләре комитеты председателе иптәш **С. В. Кафтанов** катнаштылар.

Шуның белән Милләтләр Советының Алтынчы Сессиясенең икенче утырышы ябыла.

АГРОНОМ КИҢӘШЛӘРЕ

КОК-САГЫЗНЫ ЯЗ КӨНЕ ЧӘЧҮ

Татарстан колхозларында кок-сагыз быелга кадәр көздән генә чәчелеп килә иде. Ләкин көздән чәчүнең күп кенә җитешсезлекләре бар. Көз көне һава шартларының үзгәрүчән булуы чәчү срокларын билгеләүне һәм чәчүне кыенлаштыра, чәчелгән җирләр яз көне кабыклана, чәчүлекләрне эшкәртү, чүп үләннәренә каршы көрәш читенләшә. Шунлыктан, каучуклы үсемлекләрне яз көне чәчү мәсьәләсе куела.

Быел Татарстан колхозларында кок-сагызны яз көне чәчү дәүләт планы белән билгеләнде. Бу яңа чараны үткәргәндә, иң элек, яхшы срокларда чәчү мәсьәләсен хәл итү бурычы тора.

Кок-сагызны яз көне чәчү агротехникасының беренче үзенчәлеге—орлыкны чәчү алдыннан стратификацияләүдән (суыту юлы белән борынлатудан) гыйбарәт. Дөрес стратификацияләү орлыкның тулы һәм бердәм тишелеп чыгуын тәэмин итә. Стратификация болай үткәрелә: орлык сирәк материядән тегелгән капчыкларга тутырыла. Орлык күләме капчыкның дүрттән бер өлеше чамасында алына. Аннары орлык 2—3 сәгать буена суда чылатыла һәм базга боз яки кар өстенә юка итеп һәм тигез итеп куела. Стратификацияләү вактында орлык катлавында температура һәр вакыт нульдән алып 2 градус җылылыкка кадәр булырга тиеш. Үткән ел Октябрь районы „Виктория“ колхозында температураны тикшереп тормау нәтиҗәсендә орлыклар үреп, чәчүлек һәлак булган.

Орлыкны стратификацияләүгә чәчүгә чыкканчы 20—25 көн чамасы элек салырга кирәк.

Стратификацияләү барган вакытта орлык күгәрмәсен өчен, орлыкны капчык эчендә селкү юлы белән, орлыкны әледән-әле җилләтеп торырга кирәк. Стратификацияләү вактында орлыкның үрүенә һичбер юл куймаска кирәк.

Кок-сагыз орлыгын чәчкәндә җиргә 1—1,5 сантиметр тирәнлектә күмдерелә. Башта ул әкрен тишелеп чыга. Шунлыктан кок-сагызны яхшы эшләнгән һәм дымлы туфракка мөмкин кадәр иртәрәк чәчәргә кирәк.

Туфракны эшли башларга мөмкин булу белән һәрбер колхозда кок-сагызны 1—2 көн эчендә чәчәргә кирәк. Кок-сагызны авыл тирәсендәге иң яхшы, югары уңдырышлы, 1939 нчы елның көзендә ашланган һәм сөрелгән җирләргә чәчәргә кирәк. Тунга сөрелгән җирләрне яңадан сөрмәскә, тик 6—7 сантиметр тирәнлектә яхшылап культивация үткәрергә генә кирәк. Орлык дымлы туфрак катлавына чәчелсен өчен, тунга сөрелгән җирләрне тырмалау, культивацияләү һәм бер үк вакытта тырмалау бер үк көнне үткәрелергә тиеш.

Ашламалар куллану—югары уңыш алу өчен хәл иткеч шарт. Төп ашламалар—тирес һәм минеральләр җирләр тунга сөрелгәндә яки парны эшләгән вакытта кертелә. Шуның өстенә, тунга сөрелгән җирне яз көне тырмалау алдыннан гектарга 1,5—2 центнер суперфосфат, 0,5 центнер кали тозы, 1 центнер сульфатаммоний яки 0,6 центнер аммияк селитрасы кертелергә тиеш. Әгәр дә җирне сөргән вакытта минераль ашламалар кертелмәгән булса, чәчү алдыннан туфракны эшләгән вакытта минераль ашламалар кертү нормаларын ике өлеш арттырырга кирәк. Минераль ашламалар җитешмәсә, кок-сагыз чәчелә торган җирләрне ашлау өчен кош тизәге, көл, тирес сыекчасы, компостлар, черемә кебек җирле ашламалардан файдаланырга кирәк.

Стратификацияләгәннән соң орлыклар укмашмасын өчен, аңа иләнгән һәм яхшы киптерелгән пычкы чүбе яки кызган ис чыкканга кадәр пичтә кыздырылган тары кибәге кушалар.

Чәчкечләрне көйләгәндә стратификацияләүдән соң орлык үлчәве артуы һәм аңа кушылган нәрсәнең авырлыгы исәпкә алынырга тиеш. Чәчкечләрне сай чәчүгә көйләргә кирәк.

Чәчү вактында рәт араларының киңлеге 4—5 сантиметр һәм рәтләрнең туры сызыклы булуын нык күзәтергә кирәк.

Чәчүлекләрнең рәт араларына черемә яки торф вaклары сибү бик яхшы нәтиҗәләр бирә. Аның калынлыгы 0,5—1 сантиметр булырга тиеш.

Академик Т. Д. Лысенконың тәкъдиме буенча, СССР Наркомземы шушы елның языннан кок-сагызның эре тамырларын җитештерү өчен питомник салу планын билгеләде. Татарстан колхозларында питомниклар өчен 60 гектар җир билгеләнә. Каучук җитештерүче стахановчылар, колхоз агротехниклары һәм агрономнар Т. Д. Лысенконың бу тәкъдимен элеп алырга һәм, кечкенә участкыда гына булса да, тамырларының эрелеге ягыннан чынчыннан рекордлы үсемлек үстерүгә ирешергә тиешләр. Көз көне бу питомниклардагы тамырлар казып алыналар, иң эре тамырлары яхшы ашланган, эшкәртелгән участкыга күчереп утыртылалар.

Бер үк вакытта СССР ның Ленин исемендәге авыл хуҗалыгы фәннәре Академиясе селекция теләге белән колхозларда иң эре тамырлы кок-сагызны җыю эшен оештыра. Анда авырлыгы 75 граммнан артык тамырлар кабул ителәчәк. Мәсәлән, авырлыгы 151 дән 200 граммга кадәр булган һәрбер тамыр өчен 100 сум, 201 граммнан авыр тарткан тамыр өчен 200 сум түләнә. Бу чара колхозчыларны эре тамырлы сорт җитештерү, каучуклы үсемлекләр үстерүне көчәйтү өчен көрәшкә дәртләндерергә тиеш.

Агроном *Ник. Мосунов.*



Сталинчыл өченче бишьеллык исемендәге социалистик ярышка кушылып планнарын 150 процентка үтәүче Ф. Нуреева (сулда) һәм Н. Дунаева (2 нче номерлы тегү фабрикасының 4 нче цехы стахановчылары) иптәшләр эш вакытында. А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ XX ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

ЯРЫШЫП ЭШЛӘҮ НӘТИҖӘСЕ

Чаллы районы колхозлары арасында юл төзү эшләре өчен материаллар хәзерләү һәм аларны ташу планнарын срогыннан элек үтәү өчен социалистик ярыш киң җәелә. Сарман трактын реконструкцияләүнең инициаторы—Крупская исемендәге колхоз гравий һәм агач материаллары хәзерләү һәм аларны ташу эшен төгәлләп, күпер төзү эшенә керешә.

Районның 8 колхозы юлга таш, щебень, гравий китерү планын үтәделәр. Алар арасында „Сосновка“, „Гигант“, „Алга“ колхозлары, Вахитов һәм Чкалов исемендәге колхозлар һәм башкалар бар. „Алга“ колхозының төзү бригадасы 150 кубометр гравий, һәм 100 кубометр таш хәзерләде һәм аларны юлга ташыды.

Чкалов исемендәге колхоз членнары юл төзүдә аеруча актив эшлиләр. Бу колхозның председателе район советы депутаты иптәш Мәрдиев юл төзелешенә зур игтибар бирә. Колхоз юл төзү участкысына 80,5 кубометр таш, 10 кубометр гравий ташыды һәм планны 107 процент итеп үтәде.

АЛДЫНГЫЛАРДАН ҮРНӘК АЛЫРГА

Алабуга районының „Кызыл Әләм“ һәм „Ленин көне“ колхозлары юл төзелеше эшендә алдынгы булып баралар. Бу колхозлар төзү материаллары хәзерләүне һәм аларны участкыларга ташуны төгәлләделәр.

„Дружба“ колхозы членнарыннан Тютиков һәм Селиванов иптәшләр һәр көнне норманы арттырып үтиләр.

Ләкин райондагы күп кенә колхозлар юл төзелешенә игтибар биреп җиткермиләр әле. „Пролетарий“ колхозы план буенча 50 кубометр гравий урнына бары 4 кенә кубометр ташыды. „Красный колос“ колхозы да бу тармакта үз бурычын үтәми. Бу колхозда быел күпер төзелергә тиеш иде. Колхоз күпер төзү эшенә әле дә булса керешкәне юк.

Районның юл төзелеше бүлеге работниклары колхозларга җитәрлек булышмыйлар. Районның җитәкче работниклары да бу әһәмиятле эшкә икенче чираттагы бурыч итеп карыйлар.

С. Сафиуллин.

СТАХАНОВЧЫЛАР САФЫ КИҢӘЯ

Киез итек-фетр фабрикасы (Казан) коллективы Татарстанның данлыклы XX еллыгын производствода яңа уңышлар белән каршылау өчен зур хәзерлек алып бара. Бу уңай белән цехлар, сменалар, бригадалар һәм аерым эшчеләр яңа йөкләмәләр алалар һәм йөкләмәләрен намус белән үтиләр.

Йон тарау цехында эшләүче Сафина, Закирова, Абрамова иптәшләр көнлек норманы 180—200 процент үтиләр. Чистарту-отделка цехы стахановчыларыннан Вафина, Нуриева һәм Садыйкова иптәшләр норманы 3 тапкыр арттырып үтиләр. Шуның нәтиҗәсендә цехларда хезмәт җитештерүчәнлеге шактый үсте. Көнлек план арттырып үтәлә башлады.

Б. Якупов.

Орденлы Татарстанның барлык укытучыларына, агрономнарына, врачларына, фән, культура һәм сәнгать эшлеклеләренә, барлык колхоз правлениеләренә һәм авыл советларына

Биектау районы интеллигенциясенең һәм совет-колхоз активының район җыелышының мөрәҗәгате

Атаклы датага—орденлы Татарстан АССР ның XX еллыгы якынлаша. Партиянең һәм Совет властеның Ленин - Сталин милли политикасы нәтиҗәсендә, бөек рус халкының якыннан ярдәме белән, Татарстан хезмәт ияләре социалистик төзелешнең барлык өлкәләрендә зур уңышлар ирештеләр. Бу уңышлар хезмәт ияләренең материаль һәм культура дәрәҗәләре тиз үсүенә тәэмин иттеләр.

Республикабызның XX еллыгын Татарстан хезмәт ияләре, бөтен совет халкы кебек үк, ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды һәм иптәш Сталин тарафыннан куелган бөек бурычларны хәл итүдә яңа җиңүләр белән [illegible].

Бу бурычлар арасында кешеләрнең аңында капитализм калдыкларын бетерү бурычының хәл иткеч әһәмияте бар. Бу эштә хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү эшендә культура фронты работникларына, фән, сәнгать кешеләре һәм бөтен совет интеллигенциясе гаять зур роль уйныйлар. Смоленск өлкәсенең Сычевка районы интеллигенциясе авылда бөтен массовый политик-культура эшендә активлашуны көчәйтергә чакырып мөрәҗәгать итте. Без, Биектау районы укытучылары, агрономнары, врачлары, совет-колхоз активы бу хатны тикшергәннән соң, Татарстан АССР ның XX еллыгы исемендәге социалистик ярышка кушылырга карар бирдек һәм авылда политик-агарту эшен киескен рәвештә яхшыртуны, аның сыйфатын колхозчыларның үсеп бара торган таләпләре дәрәҗәсенә күтәрүне үзебезгә бурыч итеп куйдык.

1940 нчы елда без түбәндәге йөкләмәләрне алабыз:

1. Уку өйләрен, колхоз клубларын, кызыл почмакларны авылда политик-агарту эшенең чын үзәгенә, агротехника пропагандасы, оборона һәм бәдән тәрбиясе эше үзәгенә әйләндерергә.

2. Уку өйләрен һәм колхоз клубларын кирәкле җиһазлар белән тәэмин итәргә, алар янындагы участкыларга агачлар һәм чәчәкләр утыртырга. Физкультура площадкалары һәм тирлар төзергә.

3. Һәрбер уку өе һәм клубны радиоприемник белән тәэмин итәргә һәм коллектив рәвештә радио тыңлау оештырырга.

4. Халыкара хәл турында, СССР ның экономикасы һәм тарихы буенча һәм илнең обороносы мәсьәләләре буенча районда колхозларда кимендә 300 лекция, игенчелек, терлекчелек, бакчачылык һәм яшелчәчелек буенча һәм Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе материалларын пропагандалау буенча кимендә 400 лекция, әдәбият буенча, дингә каршы темалар буенча һәм балаларны тәрбияләү буенча кимендә 200 лекция һәм медицина мәсьәләләре буенча кимендә 100 лекция укырга.

5. Уку өйләре һәм колхоз клублары янында 30 агротехника түгәрәкләре оештырып, аларга кимендә 750 колхозчыны тартырга.

6. Язгы чәчү һәм җәйге авыл хуҗалыгы эшләре чорында район күләмендә агитация-художество бригадаларын төзергә. Кыр эшләре вакытында [illegible] һәм тәҗрибәсе белән уртаклашу оештырырга.

7. Уку өйләре һәм колхоз клублары янында 20 художество үзешчәнлеге коллективлары төзергә, аларга кимендә 250 кеше тартырга.

1940 нчы елның 1 нче маена район күләмендә художество үзешчәнлеге олимпиадасы үткәрергә.

8. Татарстан АССР ның XX еллыгы датасына карата һәрбер уку өе һәм колхоз клубы янында үз колхозларының хуҗалык һәм культура үсешен күрсәтә торган күргәзмәләр оештырырга. Биектау авылында район күргәзмәсе оештырырга.

9. Татарстан АССР ның XX еллыгы датасына районда укый-яза белмәүчеләрне бетерергә һәм аз белүчеләрне укытуны төгәлләргә.

10. Колхозларда 40 физкультура коллективлары оештырырга, кимендә 1.200 кешене ПВХО, ГСО, ГТО һәм Ворошилов атысы значокларына норма тапшыру өчен хәзерләргә.

11. Казан крайны өйрәнү музеена 30 экскурсия, В. И. Ленин музеена 50 экскурсия һәм дингә каршы үзәк музейгә 50 экскурсия оештырырга, аларда кимендә 3.000 кеше катнаштырырга.

12. Һәрбер уку өе янында белешмә өстәле оештырырга, анда совет законнары һәм колхоз төзелеше мәсьәләләре буенча халыкка белешмә бирергә [illegible].

13. [illegible]

14. Уку өйләрен, колхоз клубларын кышка үрнәк булырлык итеп хәзерләргә, политик-агарту учреждениеләренә вактында ремонт ясарга һәм алар өчен ягулык хәзерләргә.

Без, политик-агарту эшен район алдында, һәрбер авыл советы һәм колхоз алдында тора торган хуҗалык-политик бурычларны уңышлы үтәүгә булышлык итәрлек итеп, стахановчылык хәрәкәтен киңәйтүгә һәм дәүләт алдындагы йөкләмәләрне вактында үтәүгә ярдәм итәрлек итеп куярга йөкләмә алабыз.

Без республикабызның барлык районнарындагы укытучыларны, агрономнарны, врачларны һәм совет-колхоз активын авылда политик-агарту эшен киескен рәвештә яхшырту өчен Татарстан АССР ның XX еллыгы исемендәге ярышка кушылырга чакырабыз.

Без Татарстан шәһәрләрендәге фән, сәнгать работникларын һәм бөтен интеллигенцияне бу инициативабызда безгә практик ярдәм күрсәтергә чакырабыз.

Без социалистик ярышта „Кызыл Татарстан“ һәм „Красная Татария“ газеталарының арбитор булуларын сорыйбыз.

Интеллигенциянең һәм совет-колхоз активының район җыелышы тапшыруы буенча:

ВКП(б) ның Биектау райкомы секретаре **Кузнецов**, Район советы башкарма комитеты председателе **Кашицин**, ВЛКСМ райкомы секретаре **Карабашев**, РОНО мөдире **Петров**, Район җир бүлеге мөдире **Строителев**, Район сәламәтлек саклау бүлегемөдире **Чакшин**, Башлангыч һәм урта мәктәп работниклары союзы райкомы председателе **Крупин**, Политик-агарту работниклары союзы райкомы председателе **Семенов**, Хохлово тулы булмаган урта мәктәп директоры орденлы **Липина**, Биектау урта мәктәп директоры **Козлов**, Укытучылар: орденлы **Лабутина** һәм **фатыйхов**, Врачлар: **Ширина** һәм **Гусева**, Агрономнар: **Никелев** һәм **Обращенко**, Буденный исемендәге колхоз председателе **Новиков**, Каймар авыл советы председателе **Архипова**.

НАВИГАЦИЯНЕ ТУЛЫ ХӘЗЕРЛЕК БЕЛӘН КАРШЫЛАРГА

***

З. АБДЕЛЬМАНОВ

ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре

***

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды халык хуҗалыгының гаять әһәмиятле тармакларының берсе булган су юлы транспорты эшенә зур игтибар итеп, су юлы транспортының артта калучылыгын якын арада бетерүне, массовый йөк ташуларны киескен рәвештә күтәрүне таләп итте.

Дөресен әйтергә кирәк, съездның бу сугышчан таләбе республикабызда чиктән тыш акрын үтәлә әле. Су юлы транспортында эшнең начар оештырылуы, 1940 нчы ел навигациясенә хәзерлекнең акрын баруы Татарстан большевикларының күптән түгел генә булып узган XXI нче өлкә конференциясендә бик урынлы тәнкыйтьләнде һәм конференция бу өлкәдә эшне юлга салу буенча үзенең конкрет күрсәтмәләрен бирде. Бурыч, хәзер ул күрсәтмәләрне су юлы транспортының барлык эшчеләренә җиткерүдән, массаны конференция карарларын үтәү тирәсенә туплаудан, навигацияне тулы хәзерлек белән каршылауны тәэмин итүдән гыйбарәт.

Орденлы республикабызның Волга һәм Кама елгаларында навигация башлануга санаулы гына көннәр калды. Навигациягә хәзерлек эше ничек бара соң? Судноларга, пристань, причал һәм склад хуҗалыкларына ремонт эше ничек тора? Ачыктан-ачык әйтергә кирәк, ремонт эшләренең барышы канәгатьләнерлек булудан ерак тора әле. Дербышка һәм Чаллы затоннарыннан башка затоннарда судноларны ремонтлау планы үтәлми. Нарком тарафыннан расланган графиканың үтәлеше бу затоннарда 3—6 процентка артка кала.

Чистай, Куйбышев һәм Аракчино затоннарында ремонт эшләре аеруча начар оештырылган. Сыйфат күрсәткечләренә җитәрлек игтибар бирелмәү аркасында, брак зур күләм алган. Мәсәлән, Чистай затонында ремонтланган „Дюканов“, „Москва“, „Балхаш“ пароходларын тикшергәннән соң, зур гына деффектлар барлыгы беленде. Чуен кою цехында брак 84 процентка җитә. Куйбышев исемендәге затонда брак быел узган елгыга караганда да арткан. Мәсәлән, узган елны брак продукция эшләү фактлары 170 булса, быел ул соңгы ай ярым вакыт эчендә генә дә 39 булган.

Бу хурлыклы хәлнең төп сәбәбен, барыннан да элек, затон җитәкчеләренең борыла алмаучылыклары, искечә эшләүләре һәм кимчелекләргә каршы киескен рәвештә көрәшмәүләре белән генә аңлатырга мөмкин. Моны раслау өчен кайбер фактларга тукталып үтик.

Социалистик ярышка һәм стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек мәсьәләсен алыйк. Бу эш затон директорлары һәм партбюро секретарьлары тарафыннан игтибар үзәгенә алынмаган. Куйбышев исемендәге затонда (директоры Тютин һәм партбюро секретаре Денисов иптәшләр) үзара социалистик ярыш договорлары төзегән эшчеләрнең 30—35 проценты (эш башыннан эшләүчеләр) нормаларын үтәмиләр. Чөнки аларга тиешле эш шартлары тудырылмаган. Эшчеләрнең һәм станокларның эшсез торулары 30—32 процентка җитә. Күп станокчылар хәрәкәте җәелдерелмәгән. Аларның саны затонда 2—3 кешедән артмый. Литейщик Сәләхеттинов, ремонтчы Ларищев, тимерче Котков, электросварщик Ларин кебек мактаулы стахановчыларның бай тәҗрибәләре башкаларга күчерелми. Социалистик ярыш договорларының үтәлеше үз вактында тикшерелми.

Чистай затонында да (директоры иптәш Завьялов) шундый ук хәл хөкем сөрә. Монда берьюлы 2—3 станокта эшләүче стахановчылар моннан 2—3 ай элек 20 дән артык исәпләнгән булса, хәзер алар 4—5 кешегә калганнар. Яңалыклар новаторы, 3—4 станокта эшләүче токарь иптәш Гибалин, тиешле эш шартлары тудырылмау аркасында, бер станокта гына эшләргә мәҗбүр булган.

Кадрларны тәрбияләү, аларны эшкә өйрәтү бу затоннарда онытылган тармакларның берсе. Бу хәл исә эш көчләренең алмашынып торуларын тудыра. Моны без—шул ук Куйбышев һәм Чистай затоннары мисалендә бик ачык күрәбез. Куйбышев исемендәге затонда, мәсәлән, узган елны 712 кеше эшкә алынган булса, 470 кеше эштән киткән. Бу факт, масса арасында тәрбия эшләренең начар булуы турында сөйли. Партоешмалар янында оештырылган агитколлективлар үзләренең җаваплы һәм мактаулы бурычларын кирәгенчә үтәмиләр. Эш участкыларында, торакларда агитаторлар сирәк булалар.

Хезмәт дисциплинасы турында партия һәм хөкүмәт карарларын кайбер урыннарда тупас рәвештә бозалар. Производствода эшне таркатучыларга, ялкауларга каршы киескен көрәш оештырмыйлар. Эшкә килү һәм эштән китү вакты исәпкә алынмый. Эшкә соңга калып килү, иртә китү күренешләрен Чистайда да, Аракчинода да еш кына очратырга мөмкин. Чистай затонында эшләүче кочегар Федоровский, тимерче Мартьянов кебек ялкауларның эш вактында эчү мәҗлесе оештырулары фактыннан тиешле нәтиҗә ясалмавны нәрсә белән аңлатырга. Партия, профсоюз оешмалары мондый фактлардан үзләре өчен тиешле нәтиҗә ясарга, хезмәт дисциплинасын ныгыту өчен барлык чараларны күрергә тиешләр.

Затоннарның партия оешмалары производство мәсьәләләре белән бик йомшак шөгыльләнәләр. Эшнең теге яки бу тармагы буенча бюро утырышларына, партоешма җыелышларына куела торган мәсьәләләр алдан тиешенчә хәзерләнмиләр. Партоешмалар үз карарларының үтәлешен тикшереп тормыйлар. Бу өлкәдә Куйбышев затоны партоешмасы аеруча начар эшли. Монда карар чыгаралар да, бик тиз оныталар. Шушы елның 28 нче январенда үткәрелгән җыелышта токарьный цехның эше, судноларга ремонтның барышы һәм тимерчелек цехындагы простойларның сәбәпләре тикшерелә. Ләкин бу карарлар эшчеләр массасына җиткерелмәгәннәр һәм тиешле нәтиҗәне бирмәгәннәр.

Коммунистларның производствода авангардлык рольләре мәсьәләсенә аерым рәвештә тукталып үтәргә кирәк. Чөнки бу мәсьәлә җидди әһәмияткә ия булып тора. Һәрбер коммунист үз эшендә үрнәк күрсәтергә, шуның белән үз арттыннан башкаларны ияртергә тиеш. Моны бездән ВКП(б) уставы таләп итә. Шулай да, кайбер коммунистлар устав таләбен үтәп җиткермиләр әле. Чистай, Аракчино, Куйбышев затоннарында коммунистларның күпчелеге производствоның төп участкыларында түгел, ә аппаратта, ярдәмче эшләрдә эшлиләр. Мәсәлән, Куйбышев затонында барлыгы 127 коммунист исәпләнә, ә турыдан-туры производствода эшләүчеләр 38 кешедән артмый. Аларның да бер өлеше үз нормаларын үтәмиләр, социалистик ярышта койрыкта сөйрәләләр. Шуңа карамастан партия оешмасы бу факттан үзенә тиешле нәтиҗәне ясамаган, бу өлкәдә эшне юлга салу буенча практик чаралар күрмәгән.

Навигация башлануга кайбер пристаньнәр дә хәзер түгел әле. Ә бит Казан һәм Кама Тамагы пристаньнәре җитәкчеләре навигациягә хәзерлекне 1 нче апрельгә төгәлләүне кат-кат ышандырганнар иде. Чынында исә эш бөтенләй башкача: пристань территорияләре һәм складлар клиентлар йөкләреннән әле дә булса бушатылмаганнар. Шуның аркасында ремонт эшләренә тоткарлык ясала. Грузчиклар өчен 263 квадрат метр күләмендә торак мәйданы җитешми, булганнары ремонтланмый. 460 кешене эченә алган Казан пристане коллективында бары тик 112 стахановчы һәм 44 ударник исәпләнә.

Бу кимчелекләрне якын арада бетерү, 1940 нчы ел навигациясенә большевистик хәзерлекне тәэмин итү—республикабызның су юлы транспорты работниклары алдында иң җаваплы бурыч булып тора. Моны үтәүгә барлык көчне, барлык игтибарны тупларга, партия-масса эшләрен хуҗалык бурычлары белән дөрес һәм нык бәйләп алып барырга, кадрларны дөрес урнаштыру һәм аларны тәрбияләү эшенә большевистик игтибар итәргә кирәк. ВКП(б) райкомнары һәм район советларының башкарма комитетлары су юлы транспортына оператив җитәкчелек итәргә, навигациягә хәзерлек эшләрен якын көннәрдә төгәлләү өчен бөтен чараларны күрергә тиешләр.

СССР Верховный Советының Алтынчы Сессиясенең эше турында чит ил матбугаты

БОЛГАРИЯ

СОФИЯ, 1 апрель. (ТАСС). „Дума“ газетасы, СССР Верховный Советы Сессиясендә иптәш Молотов докладлы турында аңлатып, болай дип яза: „Чит Ил Эшләре Халык Комиссары Молотовның Советлар Россиясе Верховный Советы алдында сөйләгән рече бөтен дөньяны борчучы сугыш турында һәм тынычлык мәсьәләләре буенча Советлар Союзы тоткан нык позицияне аңлата.

Советлар Союзы, Молотов реченнән күренгәнчә, төньякта үзенең бурычларын зур уңыш белән хәл итте. Сугыштан читтә калырга омтылып, ул, кулларына корал тотканы хәлдә, вакыйгаларне уяу күзәтеп барыр.

СССР халыклар арасында тынычлыкны тәэмин итәргә омтылып һәм үзенең турыдан-туры интересларын яклап Советлар Союзында берләшкән халыкларның интересларына империалистик көчләрнең зыян китерергә маташуларына мөмкинлек бирмәс.

Молотовның рече Россиянең нык оборона политикасының шаһите, чөнки Россия үзенең тарихи бурычын тирәнтен аңлый, ул бу бурычны читләр интереслары файдасына корбан итмәс“.

ЛАТВИЯ

РИГА, 1 апрель. (ТАСС). Латвия матбугаты СССР Верховный Советының Алтынчы Сессиясенең эшен күзәтеп бара. Бүген газеталар Карел - Фин Совет Социалистик Республикасы төзү һәм 1940 нчы елгы дәүләт бюджеты турында тулы хәбәрләр бирәләр.

ЭСТОНИЯ

ТАЛЛИН, 1 апрель. (ТАСС). Эстониядә чыга торган барлык газеталар Карел - Фин Совет Социалистик Республикасы төзү турында СССР Верховный Советы депутаты иптәш Жданов докладын басып чыгардылар. „Уус эсти“ һәм „Рахвалет“ газеталары иптәш Жданов докладын газетаның беренче битендә урнаштырдылар.

ЛИТВА

КАУНАС, 31 март. (ТАСС). „Фолькcблад“ газетасы бүген иптәш Молотов докладының тулы текстын игълан итә. Газета болай дип яза:

„СССР Верховный Советы Сессиясе утырышында Молотов докладлы—соңгы вакытта Европа политикасындагы әһәмиятле вакыйга. Бөтен дөньяның карашы Москвага юнәлгән булу гаҗәп түгел. Молотов докладлы хәзерге вакытта Европа политикасына күп ачыклык кертте. Ул беренче дәрәҗәле һәм принципиаль характерда. Бу доклад күп кенә иллюзияләрне, гайбәтләрне һәм ялган хәбәрләрне бетерде.

Бу сугышта СССР ның нейтраль булып калуы һәм барлык дәүләтләр белән дусларча мөнасәбәтләр алып барырга хәзер торуы турындагы белдерүе Молотов докладында әһәмиятле урынны алып тора. Бөтен дөньядагы тынычлык дуслары Советлар Союзының чын күңелдән булган тынычлык политикасына бер кемнең дә комачауламавын телиләр“.

ШВЕЦИЯ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ДЕКЛАРАЦИЯСЕ

БЕРЛИН, 1 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының Стокһольмнан хәбәр итүенә караганда, Швеция хөкүмәте бүген рус-фин конфликты вакытындагы политик һәм дипломатия вакыйгаларе турында һәм Швециянең позициясе турында рикcдагның ике палатасында декларация игълан иткән. Югаргы палатада декларацияне чит ил эшләре министре Гюнтер, түбәнге палатада—баш министр Гансон укыган. Хөкүмәт декларациясендә вакыйгаларга тарихи күзәтү ясала һәм үзләренең гаскәрләрен җибәреп көнбатыш державаларның төньяктагы хәлне кискенләштерергә омтылулары турында яңа мәгълүматлар китерелә. Декларациядә Швеция хөкүмәтенең позициясе турында болай диелә: „Швеция тарафыннан Финляндиягә күрсәтелгән ярдәменең киң һәм шактый зур булганлыгы финнәр ягыннан да, шведлар ягыннан да исбат ителде. Финляндиягә башка дәүләтләрдән, бигрәк тә Бөек Британия һәм Франция тарафыннан булган ярдәмгә килгәндә исә, Швеция хөкүмәте башта ук материаллар [illegible]

[illegible] Мәсәлән, 2 нче мартта, димәк, Финляндия белән Россия арасында солых турында инде сөйләшүләр барган вакытта Даладье [illegible]

[illegible] Франция тарафыннан көчле реакция

тудыруыннан Швеция һәм Норвегия хөкүмәтләренең куркуларын икрар иткән. Мондый хәл була калганда көнбатыш державалар Швециягә һәм Норвегиягә киң күләмдә сугыш ярдәме күрсәтергә хәзер торуларын һәм моңа инде хәзерлек алып барылуны белдергәннәр. Англиянең бу белдерүен шул ук көнне Франция илчесе дә яклаган. Ләкин 2 нче һәм 3 нче мартта Швеция хөкүмәте бу сораугa баш тартып җавап биргән. 5 нче мартта Финляндия хөкүмәте Швеция хөкүмәте аркылы һәм аның Москвадагы илчесе аркылы русларның элекке тәкъдимнәрен принципта кабул иткәнлеген һәм сөйләшүләрнең вакты һәм урыны турында белдерү көткәнлеген белдергән. Ул килешү төзергә тәкъдим иткән. Швеция илчесе бу турыда Москвада 6 нчы мартта иртән 11 сәгаттә хәбәр иткән. Ләкин килешү турындагы тәкъдимне руслар кире каккан. 6 нчы мартта Совет хөкүмәтенә Финляндия хөкүмәтенең Москвага делегация җибәрергә карар биргәнлеге белдерелгән. 8 нче март- [illegible]

[illegible] на кул куелган.

Черчилльнең рече

ЛОНДОН, 1 апрель. (ТАСС). Англиянең диңгез министре Уинстон Черчилль 30 нчы мартта радио буенча речь сөйләде. Черчилль болай дип белдерде: Фронттагы тынлыкның 7 айлык чоры союзниклар тарафыннан сугыш хәзерлеген көчәйтү һәм экономиканы сугыш ихтияҗларына яраклаштыру һәм шуларга туры китереп ике илнең бөтен тормышын үзгәртеп кору теләге белән бердәм хәрәкәт урнаштыру өчен файдаланылды. Аннары сугыш хәрәкәтләренең көчәюен күтәргә кирәклеген күрсәтеп, Черчилль болай диде: „Без бурычларыбызның катлауланганлыгын киметеп күрсәтмибез, ләкин хәзер, диңгездә һәм һавада дошманыбыз белән контакта урнаштыргач, аны электәгегә караганда тагын да тулырак итеп билгеләргә мөмкин. Без, үтелгәннәргә караганда тагын шактый сынаулар һәм бәләләр үтәргә тиеш икәнлегебезне үзебездән яшермибез һәм без шулай ук, Англиягә һәм Франциягә гаять зур көчләр таләп ителгәнлеген беләбез“.

Аннары Черчилль болай дип белдерде: союзникларның материал һәм кеше рессурслары, аларны тулысынча туплаганда Германия рессурсларыннан артык булачак, Германияне кирәкле булган чимал белән Европадагы күп кенә кечкенә илләрдән тәэмин итү „күп кенә илләр өчен җидди нәтиҗәләр белән бөтен дөньяны озакка сузылган сугышка китерүе мөмкин. Шуңа күрә дә, мин, сугыш кыска булыр дип бер вакытта да ышандыра алмыйм, һәм аның җиңел булачагын раслау өчен дә миндә нигезләр аз“.

Черчилль, СССР га каршы күп кенә һөҗүмнәр ясап, нейтраль илләр адресына яңадан янау белән мөрәҗәгать итте. Ул, Англия тегe яки бу илләрнең нейтралитеты белән хисаплашмаячак, чөнки бу нейтралитет Англия өчен тоткарлык ясый, дип белдерде.

Черчилльнең рече турында Англия матбугаты

ЛОНДОН, 1 апрель. (ТАСС). Черчилльнең рече уңае белән Англия газеталары Норвегиянең территориаль сулары аркылы Германиягә Швециянең тимер рудасын чыгаруга союзникларның комачаулау омтылышларына зур игътибар бирәләр. Черчилльнең речен газеталар шулай ук Румыниягә басым ясау турындагы мәсьәләне яңадан кую өчен сәбәп итеп файдаланалар. Германиягә Румыния нефтен кертү Англия матбугатын торган саен күбрәк ачуландыра бара.

Англия илчеләрен Лондонга чакыру

ЛОНДОН, 29 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, чит ил эшләре министре Галифакс Англиянең Төркиядәге илчесенә һәм Англиянең Грециядәге, Болгариядәге, Румыниядәге Венгриядәге һәм Кеньяк - Славиядәге илчеләренә хөкүмәткә доклад ясау өчен Англиягә килергә тәкъдим иткән. „Дейли телеграф энд Морнинг пост“ газетасының хәбәрләренә караганда, алар барсы да Лондонга апрель башында киләчәкләр.

Казан Радиокомитеты студиясендә. Рәсемдә: Радиокомитет солисты иптәш Гайшә Камаева микрофон алдында.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

КОЛХОЗЛАРДА ҖИМЕШ БАКЧАЛАРЫ

Хәзерге көндә Татарстан колхозларында җиләк-җимеш бакчаларының мәйданы 7.000 гектарга җитә. Быел яз һәм көз көне колхозларда 1.150 гектар мәйданда яңа бакчалар ясалачак. Шулардан 900 гектарга алмагач, 250 гектарга башка төрле җиләк-җимеш агачлары утыртылачак. Яз башында яңа бакчалар 310 гектар мәйданда ясала. Колхоз бакчаларына, шулай ук колхозчыларның, районнарда торучы эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең каралты тирәләренә яз көне утырту өчен питомниклардан 61.500 төп алмагач, 213.000 төп кура җиләге һәм карлыган куаклары бирелә. Шулар өстенә колхозларның хәзерге бакчаларында корыган һәм картайган агачлар урынына утырту өчен питомниклардан 30.500 төп алмагач җибәреләчәк.

1941 нче елда Татарстан колхозларында яңа бакчалар 2.000 гектар мәйданда ясалачак.

КИҢ КУЛЛАНУ ТОВАРЛАРЫ ҖИТЕШТЕРҮ

Татарстан Халык Комиссарлары Советы Татарстан АССР предприятиеләрендә киң куллану товарлары җитештерүне көчәйтергә карар бирде.

1940 нчы елда промышленность предприятиеләренең төп продукцияләреннән тыш 18 миллион 71 мең сумлык промышленность товарлары эшләнәчәк. Зур предприятиеләр үзләренең төп продукцияләрен эшләгәндә кала торган материаллардан металл савытлар, кроватьлар, примус горелкалары, мебель, карандаш һәм башка промтоварлар эшләүне үзләштерәләр. Шулай ук өстәмә рәвештә өс-баш киемнәре, аяк киемнәре җитештерелә. Азык промышленносте предприятиеләре өстәмә рәвештә 6 миллион 756 мең сумлык ит-сөт продуктлары һәм башкаларны эшләп чыгаралар.

ЯШЕЛЧӘ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

Татарстан колхозларында быел яшелчә чәчү мәйданы шактый киңәя.

Узган ел колхозларда 11.570 гектар мәйданга яшелчә чәчелгән иде. Быел яшелчәләр чәчү мәйданы 13.600 гектар итеп билгеләнде. Шул исәптән 3.600 гектар кәбестә, 2.100 гектар кыяр, 1.150 гектар помидор, 1.900 гектар чөгендер, 1.900 гектар суган, 600 гектар кавын чәчелә. Алардан калган 2.350 гектар мәйданга башка төрле яшелчә культуралары чәчеләчәк. Казанга якын булган 8 районда яшелчәләр чәчү мәйданын киңәйтүгә аеруча әһәмият бирелә. Яшелчә җирләре күбесенчә тракторлар көче белән сөреләчәк.

ТАТАРСТАНДА

Быел Татарстан колхозларында җиләк-җимеш бакчаларын киңәйтү һәм яшелчә культураларын үстерүне яхшырту чараларына авыл хуҗалыгы Банкысы аркылы 535 мең сум кредит билгеләнде.

Житен комбинатында эшләүче эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең балалары өчен Лебяжье күле янындагы нарат урманында пионерлар лагеры төзелә. Анда быел 400 бала ял итәчәк. Лагерьны төзүгә 40 мең сумнан артык акча җибәрелде.

1940 нчы елда Татарстан районнарында колхозчы хатын-кызлардан 2.500 тракторчы хәзерләнә.

Татарстандагы кустарьлардан 100 кеше быел СССР ның төрле шәһәрләренә экскурсиягә җибәрелә. Экскурсияләрне оештыруга 34.500 сум акча билгеләнде.

ЯШ ФИЗИКЛАР ОЛИМПИАДАСЫ

Халык мәгарифенең Казан шәһәр бүлеге, университет һәм балаларның үзәк техника станциясе апрель аенда яш физикларның олимпиадасын үткәрергә карар бирделәр. Олимпиадада 7, 8 һәм 9 нчы класс укучылары катнашачак.

Беренче тур апрельнең 5 еннән 10 ына кадәр мәктәпләрдә үткәрелә. Олимпиадада катнашучылар физикадан 3 задача эшләргә тиешләр. Һәрбер задачаны дөрес эшләгән өчен 5 очко бирелә.

Беренче тур вактында кимендә 12 очко алган укучылар 2 нче турда катнашалар. Алар 3 сәгать вакыт эчендә физикадан тагын 3 задача хәл итәргә тиешләр.

Өченче тур апрельнең 15 ннән 20 сенә кадәр университетта үткәреләчәк.

6 премия билгеләнде: олимпиадада җиңүчеләр өчен 3 һәм укучылары күп катнашкан мәктәпләр өчен 3 премия.

(ТатТАСС).

Почта челтәре киңәйтелә

Хәзерге көндә Татарстанның шәһәрләрендә һәм авылларында 396 урында элемтә бүлеге, 392 урында элемтә агентлыгы, һәм 64 районда элемтә конторалары бар. Быел 5 шәһәрдә яңа конторалар һәм 15 авылда элемтә агентлыклары ачыла. Элемтә конторaларын һәм агентлыкларны биналар белән тәэмин итү хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары башкарма комитетларына йөкләнде. Элемтә конторaларын җиһазлау өчен 18.700 сум акча җибәрелде.

ЭМИЛЬ ЗОЛЯ

(Тууына 100 ел тулуга карата)

Эмиль Золя XIX нчы йөзнең икенче яртысында иҗад иткән күренекле француз язучысы. Ул 1840 нчы елның 2 нче апрелендә Франциянең Экс шәһәрендә инженер семьясендә туа. Укуын тәмам иткәннән соң Парижга күчеп китә һәм хезмәткәр булып төрле эшләрдә эшли. Бик тиз вакыт эчендә Эмиль Золя үзен яхшы журналист итеп таныта. Ләкин ул журналист булып түгел, бәлки үзенең күп санлы романнары белән атаклы.

Аның иң зур әсәре „Ругон-Маккары“ исемле күп томлы романнар сериясеннән тора. Бу романнар өстендә ул 22 ел буена эшләгән. „Ерткыч кеше“, „Нана“, „Акчалар“, „Тар-мар“, „Тозак“, „Жерминаль“ һәм башка романнарында Золя капиталистик җәмгыятнең коточкыч тормышын һәм горефгадәтләрен сурәтләде. Бу романнарда барлык социаль төркемнәр гәүдәләнгән. Монда бозыклыкларга баткан арестократия дә, ерткыч капиталистлар дөньясы да, „сайланма җәмгыят“ дәрәҗәсенә күтәрелергә янып йөргән урта һәм вак буржуазия дә бар. Монда эксплоатация белән изелгән хезмәт иясе массасы да бар.

„Лурд“, „Рим“ һәм „Париж“ романнарында чиркәүнең сатлыклыгы һәм реакционлыгы гәүдәләнә. 1885 нче елда чыккан „Жерминаль“ әсәрендә ул хезмәтнең һәм капиталның көрәшен күрсәтә. Бу әсәрнең кул язмасында ул: „Капиталистик җәмгыятькә удар ясалды, ул бу ударлардан какшый“ ди.

Эмиль Золяның әсәрләре үз



заманында гаять зур роль уйнадылар. 1894 нче елда Франция генеральный штабы офицеры Дрейфус дәүләткә хиянәт итүдә ялган гаепләнеп, гомерлеккә каторгага хөкем ителә. Антисемитлар һәм монархистлар тарафыннан уйдырмаланып ясалган Дрейфус эше Франциянең алдынгы кешеләрендә көчле нәфрәт кузгата. Шул уңай белән Золя Дрейфусны яклап чыга һәм республика президенты исменә „Мин гаеплим“ дигән исемдәге хатын бастырып чыгара. Ул бу хатта Франция хөкүмәтен һәм судын гаепли. Һичбер нигезсез гаепләнгән еврей - офицер Дрейфус эшен яңадан карауны таләп итә. Берничә ел барган көрәштән соң, Золя һәм аның дуслары Дрейфусның аклануына ирешәләр. Бу вакыйга гаять зур әһәмияткә ия булып тора. Чөнки ул милитаристларның һәм руханиларның провокацион чыгышларына, аларның Франциядә ачыктан-ачык реакция режимы урнаштырырга маташуларына отпор бирде.

Дрейфусны яклап алып барылган көрәштә Золягә бик зур кыенлыкларга очрарга туры килә. Эш Золяның үзен суд җаваплылыгына тартуга һәм аны Франциядән Англиягә куугa кадәр барып җитә. Золя нак менә шушы елларда Жорес белән һәм Франциянең социалистик хәрәкәте белән якынлаша. Язучы үзенең соңгы елларында җәмгыятне социалистик нигезләрдә үзгәртеп кору уе белән яна. Ләкин реформистик хәрәкәт йогынтысы нәтиҗәсендә ул утопик иллюзияләргә төшә.

Совет укучылары Эмиль Золяне зур һәм намуслы художник булуы өчен яратып укыйлар. Ул буржуаз җәмгыятнең варварлык гадәтләрен, капиталистик эксплоатацияне фаш иткән һәм капитал белән хезмәтнең көрәш темасын дөнья әдәбиятына иң беренче булып керткән язучы.

Мәктәп балалары В. В. Маяковский юбилеенә хәзерләнәләр

Казан шәһәрендәге мәктәп балалары В. Маяковский юбилеенә зур күтәренкелек белән хәзерләнәләр. 41 нче номерлы мәктәпнең өлкән классларында укучылар еллык көнендә Маяковскийга багышлап әдәби-художество кичәсе үткәрәләр. Кичәдә Маяковскийның иҗады турында иң яхшы укучылардан бер кеше доклад ясаячак. Концерт бүлегендә мәктәпнең иң яхшы сөйләүчеләренең чыгышлары булачак.

(ТатТАСС).

Олимпиадага хәзерләнәләр

Кукмара район үзәгендәге 1 нче номерлы урта мәктәп укучылары художество үзешчәнлеге олимпиадасына хәзерләнәләр. IX нчы класс укучылары, балалар тормышыннан алып язылган „Шикле кеше“ дигән пьеса һәм үзбәк, татар халык биюләреннән номерлар хәзерлиләр.

V нче „б“ классы укучылары „Безнең рапорт“ дигән пьесаны өйрәнәләр. VI, VII һәм X нчы класс укучылары төрле номерлар хәзерлиләр. Мәсәлән, VI нчы класс укучыларыннан Мансура Кәшипова гармонда „Эрбет“, „Танкистлар маршы“, мандолинада „Гармон“, „Комсомолка Гөлсара“ көйләрен, Мансур Габдрахманов гармонда „Яш егетләр, яш кызлар“ һәм башка көйләрне яхшы итеп башкара алалар.

IV нче класс укучылары Г. Степанов һәм И. Сәлимова үзләре иҗад иткән шигырьләрен укыячаклар. *М. Фазлыев.*

ЕЛГАЛАРДА

2 нче апрельгә каршы бер тәүлек эчендә Волга суы Вязовые янында 33 сантиметр, Югары Ослан янында 40 сантиметр, Кама Тамагы янында 23 сантиметр артты. Ташу башланганнан бирле Югары Ослан янында арткан су 156 сантиметр булды.

Кама суы бер тәүлек эчендә Красный Бор янында 16 сантиметр, Чистай янында 45 сантиметр, Лаеш янында 42 сантиметр артты.

Ока елгасында Белов янында сирәк боз ага. Рязань янында 74 сантиметр, Касым янында 23 сантиметр су артты. Агыйдел суы Бирский янында 32 сантиметр, Миша суы Рождествено янында 50 сантиметр, Казанка суы Арча янында 8 сантиметр артты.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Тапталганнар. А. Шакиров дигән шофер йөк автомобиленә икмәк төяп, Декабристлар урамыннан барган вакытта Кәрим Мөхәммәтҗанов исемле 44 яшьлек кешене таптатып үтергән. Шакиров җавапка тартыла.

Шул ук урамда билгесез шофер җиңел автомобиль белән килгәндә бер хатынны таптатып үтергән. Хатынның кесәсеннән Екатерина Салмина исеменә язылган документ табылган. Таптатучы шоферның кем икәнлеге тикшерелә.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
5 нче апрельдә, шулай ук 6 нчы апрельдә көндез һәм кич
ТАНЯ
Талоннар белән кертелми.
Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
3 һәм 4 нче апрельдә
В. Шкваркин әсәре премьера
КУРКЫНЫЧЛЫ СУД
Талоннар белән кертелми.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
Бүген, 3 нче апрельдә
ФАЙДАСЫЗГА САКЛАНУ
Иртәгә, 4 нче апрельдә
ИРЕК
Талоннар белән кертелми.
Кич 8 сәгатьтә башлана.
Коллектив рәвештә килү өчен 29—64 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә
ЗУР ЦИРК УЕНЫ
ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ
ЯРЫШЫ
ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ
Уен кич 8 дә башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы художестволы фильм ЗУР [illegible]РМЫШ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ШӘХСИ ЭШ
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 5, 6-30, 8-20 һәм 10 да.	КАБАРДА АТЛЫСЫ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышсыз фильм Дипкурьер сумкасы
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	КЕЧКЕНӘ АНА
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ТАШЛАНДЫК